ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

**«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының $2^1$ һәм 18 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2019 елның 23 октябрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында» 2010 елның 25 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2010, № 12 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 5, № 6 (II өлеш), № 7, № 11 (I өлеш); 2015, № 4; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 41 (I өлеш), № 85 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 38 (I өлеш), № 92 (I өлеш); 2019, № 49 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $2^1$ статьяның 2 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $3^1$ пункт өстәргә:

«$3^1$) 2017 елның 1 гыйнварына кадәр расланган территорияне планлаштыру проектының (вәкаләтле федераль башкарма хакимият органы раслаган планлаштыру проектларыннан һәм территорияне ызанлау проектларыннан тыш) составын һәм эчтәлеген Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 42 статьясындагы 3 өлешенең 2 һәм 3 пунктлары, 4 өлешенең 7 пункты таләпләренә туры китерү очракларын билгеләү;»;

2) 18 статьяда:

а) исемендә «, әлеге документларга үзгәрешләр кертү һәм документларның гамәлдә булуын туктату тәртибе» сүзләрен өстәргә;

б) 1 өлешнең 1 пунктында «$1^1$ өлешендә» сүзләрен «$1^1$ һәм $12^{12}$ өлешләрендә» сүзләренә алмаштырырга;

в) 14 өлештә «егерме биш көн» сүзләрен «15 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

г) 16 өлештә «егерме көн» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

д) 17 өлештә «егерме көн» сүзләрен «10 эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

е) 18 өлештә «биш көн» сүзләрен «биш эш көне» сүзләренә алмаштырырга;

ж) түбәндәге эчтәлекле $20^1$ өлеш өстәргә:

«$20^1$. Территорияне планлаштыру документларына үзгәрешләр кертү, әлеге документларның яисә аерым өлешләренең гамәлдә булуын туктату, әлеге документларның аерым өлешләрен кулланылырга тиеш түгел дип тану документларны әзерләү һәм раслау өчен Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексында һәм әлеге статьяда билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2019 ел, 16 ноябрь
№ 86-ТРЗ